СОВЕТ ГОРОДА ЗАИНСКА
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Орджоникидзе, д. 49, г.Заинск, 423522

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЗӘЙ ШӘҺӘР СОВЕТЫ
Орджоникидзе ур.,49 йорт, Зәй шәһәре,423522

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

29.09.2022 г. Заинск № 97

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» 2013 елның 29 октябрендәге 129 номерлы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәр Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 декабрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проекты буенча фикер алышу буенча гавами тыңлаулар беркетмәсе һәм гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә нигезендә, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясына, Зәй шәһәре Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Зәй шәһәр Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» 2013 елның 29 октябрендәге 129 номерлы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәр Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 24 статьяның 7 пункты 7.1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.1. Җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалану төрләре; җир кишәрлекләренең иң чик (минималь һәм (яисә) максималь) күләмнәре һәм рөхсәт ителгән төзелешнең, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең иң чик параметрлары:

| Рөхсәт ителгән файдалану төренең коды * | Рөхсәт ителгән файдалану төренең аталуы * | Капиталь төзелеш объектларын төзү һәм реконструкцияләүнең рөхсәт ителгән иң чик күләмнәре һәм чик параметрлары | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | җир кишәрлегенең үлчәме | катларның чик саны һәм төзелешнең чик биеклеге | максималь төзелеш проценты | җир кишәрлекләре чикләреннән минималь чигенүләр |
| **Рөхсәт ителгән куллануның төп төрләре** | | | | | |
| 3.5 | Мәгариф | билгеләнми | билгеләнми | 80 % | 5 м. Төзелеш шартларында чигенү яки кызыл линия буенча биналар, корылмалар һәм төзелмәләрнең урнашуы рөхсәт ителә. |
| 3.9 | Фәнни эшчәнлекне тәэмин итү | билгеләнми | билгеләнми | 100 % | билгеләнми |
| 1.14 | Авыл хуҗалыгын фәнни яктан тәэмин итү | билгеләнми | билгеләнми | 100 % | билгеләнми |
| 12.0 | Гомуми файдаланудагы җир кишәрлекләре (территорияләр) | билгеләнми | | | |
| **Рөхсәт ителгән куллануның ярдәмче төрләре** | | | | | |
| 3.1 | Коммуналь хезмәт күрсәтү | билгеләнми | билгеләнми | 100 % | билгеләнми |
| 4.9 | Автотранспортка хезмәт күрсәтү | билгеләнми | билгеләнми | 100 % | билгеләнми |
| 5.1 | Спорт | билгеләнми | билгеләнми | 100 % | билгеләнми |
| **Рөхсәт ителгән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төрләре** | | | | | |
| 4.4 | Кибетләр | билгеләнми | билгеләнми | 100 % | билгеләнми |
| 4.6 | Җәмәгать туклануы | не устанавли-вается | билгеләнми | 100 % | билгеләнми |
| 8.3 | Эчке хокук тәртибен тәэмин итү | билгеләнми | билгеләнми | 100 % | билгеләнми |

».

2. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәр Советының оештыру бүлегенә әлеге карарны Зәй муниципаль районының рәсми сайтында

(http://zainsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны җир мәсьәләләре, экология һәм торак-коммуналь хуҗалык буенча даими комиссиягә (Р.В.Әгъләмов) йөкләргә.

**Совет Рәисе** **Р.Г. Кәримов**